ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
КАРАР

2023 ел, 16 октябрь № 209

Апас муниципаль районы җирле үзидарә органнарында гражданнар һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карар итте:

1«Апас муниципаль районы җирле үзидарә органнарында гражданнар һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2016 елның 16 апрелендәге 34 номерлы карары белән расланган Апас муниципаль районы җирле үзидарә органнарында гражданнар һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

1.5.1 пунктында «электрон документ рәвешендә» сүзләреннән соң «, шул исәптән «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып» сүзләрен өстәргә (алга таба - Бердәм портал),»;

3.3 пунктының беренче абзацында «Язма мөрәҗәгатьтә» сүзләрен «Язма формадагы мөрәҗәгатьтә» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктының җиденче абзацында «Язма мөрәҗәгатьтә» сүзләрен «Язма формадагы мөрәҗәгатьтә» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктының беренче абзацында «язмача мөрәҗәгатькә» сүзләрен «язма формадагы мөрәҗәгатькә» сүзләренә алмаштырырга;

3.7 пунктта «электрон почта адресын» сүзләрен «шулай ук электрон почта адресын күрсәтә йә Бердәм порталда шәхси кабинетның адресын (уникаль идентификаторын) файдалана,”;

4.15 пунктта «вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә,» сүзләреннән соң «яисә гражданның Бердәм порталдагы шәхси кабинетының адресы (уникаль идентификаторы) буенча» сүзләрен өстәргә.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башлыгы
Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы Рәисе
А.Г. Җиһаншин